ИСПОЛНИТЕЛЬНЫМ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«КАРМАЛКИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Геодезическая ул., дом 38 А,
село Мордовская Кармалка,
Лениногорский район, 423298

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КАРМАЛКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Геодезия урамы, 38 А йорт,
Мордва Кармалка авылы,
Лениногорск районы, 423298

Тел./факс : (8-85595) 3-60-59, Karmal.Len@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2022 елның 20 сентябре** **№ 8**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2022 элның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә, «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1 Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында»;

б) карарның 1 пунктында «Муниципаль берәмлек башкарма комитеты» сүзләрен «муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга;

в) «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карары 1 нче кушымтасының исемендә «муниципаль берәмлекнең башкарма комитетында (туганнары булган) сүзләрен «муниципаль берәмлектә»сүзләренә алмаштырырга;

г) Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карары 2 нче кушымтасының «муниципаль берәмлекнең башкарма комитетында (туганнары булмаган) сүзләрен «муниципаль берәмлектә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мордва Кармалка авылы, Геодезия ур., 38 а йорт, 2 корылма (административ бина), Нагорный ур., 33 йорт (авыл мәдәният йорты) адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninoaorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Кармалка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы

О.В.Кириллова